**Тема:** “Яхшы сүздән – яхшы эшкә” (6-11 сыйныф)

**Максат:**

1. Укучыларны “Яхшы сүздән – яхшы эшкә” дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта яхшы дус табарга ярдәм итү.
2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
3. Укучыларда тирә- юньдәгеләрне хөрмәт итәргә, яхшы эшләр генә эшләргә, матур сүзләр куллана белергә.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Бөтен кешегә дә булышу- яхшы сүз, хаерле эш, һичшиксез, кире кайта икәнен аңлап, Аллаһ ризалыгы өчен изгелекләр эшләүдә башкалар белән ярышырга омтылу.
- Башкаларның тәртибен күреп үзеңнекен төзәтә белергә, хаталарыңны вакытында күрергә өйрәнү.
- Үз гаебеңне таный белү, гафу үтенә белү – бик кирәкле сыйфат икәнен аңлау.
- Аллаһ ризалыгы өчен начарлыкка яхшылык белән җавап кайтарырга омтылу.

**Эпиграф:**

- *“Әдәм яхшылыгы сүз белән” /Татар халык мәкале/.*
- *“Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен”/Татар халык мәкале/.*

**Дәрес барышы.**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз. Хикәягә исем кушыгыз.

*Бер бабай бик картайган. Аяклары йөрмәгән, колаклары ишетмәгән, тешләре коелып беткән. Ул ашаганда авызыннан аккан, ризыгы коелган. Малае белән килене аны табынга утыртмый башлаганнар. Аның белән тупас итеп, кычкыргалап кына сөйләшкәннәр.*

*Килене ирен бабайны куып чыгарырга күндергән. Кием урынына бабайга пычрак, иске ат өстенә яба торган одеял биргәннәр. Ир белән хатын малайларын одеял алырга җибәргәннәр.Озакламый малай кереп бабайга одеялны биргән. Ул одеялны алгач, бер генә кисәк булуын күргән. Шуннан малайдан сорыйлар:*

*- Нигә одеялны кистең?*

*Малай әйткән:*

*- Син картайгач калган одеялны сиңа бирермен.*

*Ир белән хатын бер-берсенә карaганннар да елап җибәргәннәр. Аларга бабайны рәнҗетүләре өчен бик оят булган. Шул вакыйгадан соң алар бик әйбәт яши башлаганнар: бабайга ачык йөзле, тәмле телле, михербанлы була башлаганнар.*

- Хикәягә кушкан исемнәрен әйтегез.

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүген без нинди темага сөйләшәбез?
- Яманлык, тупаслык турында.
- Дәреснең темасы- яманлыкның капма каршысы. Нәрсә турында булыр дәрес?
- Яхшы сүзләр, матур эшләр турында (“Яхшы сүздән – яхшы эшкә”).

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. Ата-анага игътибарсызлык гафу ителми.**

- Әлбәттә, малаеның һәм килененең усаллыгы үзләренә кире әйләнеп кайтачак.

- Ата-анага игътибарсызлык  гафу ителми. Ата- ананы, туган илне ярату бишектән башлана. Гаиләдән башлана ул башка кешеләргә хөрмәт белән карау.

- “Анаң кабере янында еларга туры килмәсен”,- ди халкыбыз. Әти-әниләр исән чагында кирәкмәгән гамәлләр кылмаска, авыр сүзләр әйтмәскә кирәк.

***Фәнзаман Батталның  “Тормыш сабаклары”*** язмасында түбәндәге юллар бар:

*“Әткәм яки әнкәм кабере янына бассам, сәер дә, гаҗәеп тә бер уй туа: гүрләренә төшеп, һәр икесен йомшак кына сөясем һәм...гафу үтенәсем килә. Еллар үткән саен, ныграк уйлыйм: үзләренә каршы да әйткәләгәнмен, кайбер сүзләрен дә тыңламаганмын, ярдәм итүем дә чамалы булган... Үземне юатып та карыйм. Мондый чакларда көянтәләп су ташуларым да, көннәр буе утын яруларым да, үсеп җиткәч вә аерым яши башлагач, яраткан чәйләрен , кирәкле даруларын юнәтеп җибәреп торуым да, бүләкләр, күчтәнәчләр белән кайтуларым да искә төшә. Тик бераздан юанычларым кабат җимерелә - игелегем бик тә, бик тә аз тигән... Үләр алдыннан һәркайсы рәхмәт әйтте, бәхиллеген бирде, югыйсә. Мин бу хакта һичвакыт язмам дип уйлаган идем. Кинәт болай уйладым :”Туктале, хәзерге малайлар һәм кызлар да ялгышып яшәми микән? Аларның бер генә сүзләрен тыңламау  гомер буе үкендерә икән бит...”*

*...Менә сиңа әтиең нинди дер йомыш куша. Кушканны, әйткәнне үзеңә зур бәхет һәм мәртәбә санап, җиренә җиткереп үтә.*

*Синең тәртипсезлекне күреп, әниең ничек өзгәләнә! Монысын да мәңгелек итеп исеңдә калдыр, әниең бу дөньядан киткәч үкенмәслек булсын. Яхшы бел: олуг табигать законнары бозылмаса, өлкән буын синнән иртәрәк үлә. Шомлы тоелыр бу сүзем, бераз куркытыр да. Әмма нишләмәк кирәк, тормыш агышы шундый. Үкенүләрем кимрәк булсын дисәң, алар исән чакта карашларына күләгә төшермә, яхшы укуың, матур яшәвең, игелекле гамәлләр кылуың белән сөендер.Ә ата-ана, гүргә кергәч тә, сиңа бәхет тели.”*

- ***Начар сүз әйтеп, өлкәннәрнең хәтерен калдыргансың икән, гафу үтен. Үз гаебеңне таный белү, гафу үтенә белү – бик кирәкле сыйфат.***

**2. «Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр вә яманрактыр”.**

Каюм Насыйриның  «Китаб – әт – тәрбия» әсәрендә түбәндәге юллар бар: **(64 нче тәрбия)**

- *«Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр вә яманрактыр, ягъни телдән әйтелгән ачы вә кабәхәт сүзләрнең адәмгә тәэсире тәнеңне пычкы белән кискәннән дә ачырактыр. Әй, угыл, һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма, ягъни яман сүз әйтмә... Әмма бер сүзне син кулай хисаплап әйтсәң дә , кешенең күңеленә бик каты тияр.Әй,угыл, каты сүзле булма. Изге холык вә йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китәдер. Кешегә ашыгып сүз әйтмә вә уйламыйча  ашыгып җавап бирмә.*

***89 нчы тәрбия.***

- *“Әй, угыл, кешенең күңеленә хилаф килә торган (үпкәләтә торган) сүзне телеңә китермә. Бер сүзне син уйламыйча әйтеп җибәрерсең, ишеткән кешенең күңеле җәрәхәтләнә торган сүз булыр, күңеле рәнҗер. Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан.”*

- Әлбәттә, балалар, начарлыкны эшләмәскә кирәк, чөнки күңел ярасы төзәлми. Бигрәк тә әти-әнинең хәтерен калдырырга ярамый. Балалар, уйлап карагыз әле: сезнең кайчан булса да әтиегез яки әниегезгә авыр сүз әйткәнегез юкмы? Сорауга җавапны үзегез үзегезгә генә биреп карагыз.

- Әйе, кайчагында үзебез дә уйламыйча, иң якын кешеләребезнең хәтерен калдырабыз. Кызулык белән әйтелгән сүз әти-әнинең йөрәгенә пычак булып кадалганы турында уйлап бетермибез шул.

**3. Гафу үтенү һәм  кичерә белү яки хатаны вакытында төзәтү. Тәүбә.**

- Бөтен кеше дә хата җибәрә, ләкин аны вакытында күреп төзәтә белергә тиешсең.
- Кешене үпкәләтсәң, хатаны ничек төзәтеп була, сезнеңчә?

- *Кешене үпкәләтсәң, рәнҗетсәң, иң яхшысы- вакытында гафу үтенү.*

- Ни өчен бик аз гына кешеләр гафу үтенәләр?

- *Әлбәттә, бу эш бөтен кешенең дә хәленнән килми. Бары тик көчлеләр башын иеп, хаталарын таныйп, үкенеп, Аллаһның ачуыннан куркып үз гаепләрен таныйлар.*

- Ни өчен гафу үтенгән кешене гафу итәргә кирәк?

- Гафу үтенгән кешене гафу итәргә кирәк. Ул бит хатасын таныган. Шуны да истә тотарага кирәк: бу адым аның өчен бик авыр һәм кешенең көчсезлеген түгел, ә киресенчә, аның кечле шәхес икәнен күрсәтә.

- Кичерелгән кеше үзен ничек хис итә?

- Ул бәхетле- аның өстеннән зур тау төшкән шикелле була.

**4. Танылган шәхескә сүз бирик.**

- Томас Фуллер әйткән:

- *"Иң начар кешеләр, кичерергә теләми торган кешеләр".*
  /Фикерләшү/

**5. Телдә булган тупаслык яки ягымлылык – кеше холкының көзгесе.**

Сорауларга җавап:

- Нәрсә ул телдә булган тупаслык һәм ягымлылык?

- Тупаслык- ул кешене хөрмәт итмичә, кычкыргалап, кимсетеп, аны мыскыл итеп сөйләшү. Ягымлылык, киресенчә, кешене хөрмәт итеп, аны җайлап, яратып сөйләшү.

- Телдә булган тупаслык яки ягымлылык – кешенең көзгесе. Күңелендә булганы- аның телендә дә, йөзендә дә, кылган эш- гамәлендә дә чагыла. Кайбер чакта кеше бик тәмле телле булырга тырыша, матур сүзләр әйтә, ләкин әгәрдә күңеле изгелектә булмаса, аның ике өйзлелеге башкаларга бик тиз ачыклана.

- Телдәге татлы сүз, ачык йөз безнең кылган эшләребез белән бергә генә яхшылык булып кабул ителә.

**6. Начарлыкка яхшылык белән җавап кайтару турында**.

- Ничек соң яхшы күңелле кеше булырга? Кичен йокларга ятканда усал кеше, ә иртән торганда яхшы булып булмый бит. (Көн саен үз-үзең өстендә эшләргә кирәк).
- Әйе, бездә яхшы кеше булу теләге булырга тиеш, ләкин бу гына җитми.
- Теләктән кала кешедә нинди сыйфатлар булырга тиеш?
- Иң беренче чиратта, намуслылык. Бар кеше дә намус белән яшәсә, бу дөньяда законнар да кирәкмәс иде. Намус бөтен кылган эшләр белән дә җитәкчелек итәр иде.
- Нәрсә соң ул намус?
- Намус – кешенең эчендәге хис, ул аны оялырга мәҗбүр итә.
- Намус кешене начар гамәлләре өчен җәфалый, ул кылган эшләреңне анализларга өйрәтә.
- Намус – ул кешенең холкы. Намусы булмаган кеше үзен бик ямьсез тота.

- Начарлыкка яхшылык белән җавап кайтарырга өйрәнгән кешене башкалар аңлап бетермәсәләр дә (вәт җүләр дип!)- ләкин ул кеше бик саваплы була, аның үз гонаһлары да җиңеллек белән кичереләчәк.

**7. Безнең киңәшләр.**

- Әти- әнинең рәнҗешеннән бик нык курык.
- Бөтен кеше белән матур сөйләш, "тәмле телле" бул.
- Дусның, теләсә нинди кешенең кадерен бел. Аны үпкәләтсәң- гафу үтен.
- Үпкәләп йөрмә, үч саклама- гафу итә бел.
- Кичерүне көтмичә, үзең барып дуслаш.
- Кешеләрдәге яхшылыкны күрә бел.
- Олыларга булыш.

- Бәләкәчләрне, кызларны сакла.
- Бөтен кешегә дә булыш- яхшы сүз, хаерле эш, һиччиксез, кире кайта.

- Без тирә- ягыбызга бары тик яхшылыклар гына китерергә тиеш.Табигатьне, туган җиребезне, планетабызны сакларга тиешбез. Үз- үзегезне яхшы эшләр эшләргә генә күндерегез. Бүген үк яхшылыклар эшли башлагыз.

**8. Мәкальләр дөньясында.**

- Күз яше бар икән– намус та бар.
- Кемгә авыр? Үч саклаучыга.
- Әдәм яхшылыгы сүз белән.
- Сүзе акның йөзе ак.
- Һәр ишеткәнен сөйләгән һич теләмәгәнен ишетер.
- *Сүз өч төрле: бер төрле сүз бар— бел дә сөйләмә; икенче төрлесе — белмә дә, сөйләмә дә; өченчесе — бел дә сөйлә.*

(Соңгы мәкаль буенча фикер алышу).

**9. Изге Коръән китабыннан.**

- Аллаһы Тәгалә әйтте:

- ***Яхшылык эшләргә ашыгыгыз*** *(Коръән,78).*
- ***“Дәхи тәүбә итеп төзәлегез вә изге гамәлләр кылу белән Раббыгызның ярлыкавына һәм җир, күкләр киңлегендә булган җәннәтләр тарафына ашыгыгыз!”*** *(Гымран:133).*
- ***“Әгәр яхшылыклар кылсагыз, үзегез өчен яхшылык кылган буласыз, вә әгәр явызлыклар кылсагыз, янә үзегез өчен явызлык кылган буласыз”*** *(Бәни Исраил: 7).*

- Бу дөньяда яхшылыклар, изгелекләр чәчсәк, дөньяда һәм ахирәттә изгелек урачакбыз. Бу дөньяда явызлыклар чәчсәк, дөньяда һәм ахирәттә явызлык урачакбыз.

**10. Хәдисләр:**

- *Үзеңә нәрсә теләсәң, башкаларга да шуны телә.*
- *Игелекле эшләрне тавышсыз гына башкарыгыз.*
- *Һәр изгелек -сәдака.*

/Фикер алышу/

**IV. Рефлексия.**

**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.

- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?*(*Әдәм яхшылыгы сүз белән. Ата-анага игътибарсызлык гафу ителми).

- Ни өчен кешене үпкәләтсәң, рәнҗетсәң, иң яхшысы- вакытында гафу үтенү?

**-** Дөньяда яшәүче һәркем ягымлы сүз көтә. Үзенә карата кайгыртучанлык, кадер-хөрмәт, игътибарлы мөнәсәбәт өмет итә. Шуңа күрә, һәрберебез тәмле телле булыйк. Җылы сүзебезне, яхшы мөнәсәбәтебезне кызганмыйк. Юкка гына халкыбыз

- ***“Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен”*** димәгән.

**V. Өйгә эш.**

- Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. “Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен” дигән тема буенча фикер алышу.
2. “Иң начар кешеләр, кичерергә теләми торган кешеләр” дигән темага җавап әзерләү.